СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 9-13 от « 23 » марта 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең 2021 елның 26 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 9-6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең 2021 елның 26 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 9-6 номерлы карарына Мамадыш районы прокуратурасының 2022 елның 25 январендәге №02-01-19-2022 протесты, Россия Федерациясенең Җир һәм Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 27 статьясының 1 өлешендәге 1.1 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 77 статьясы нигезендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составында авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләре, хуҗалык эчендәге юллар, коммуникацияләр, тискәре йогынтыдан җирләрне яклауны тәэмин итү өчен билгеләнгән урман утыртмалары, су объектлары (шул исәптән су агымында терәү корылмалары барлыкка китергән һәм буа аквакультураларын гамәлгә ашыру максатлары өчен файдаланыла торган буалар) биләгән җирләр, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм беренчел эшкәртү өчен файдаланыла торган капиталь төзелеш объектлары, капиталь булмаган корылмалар, корылышлар, федераль законнарда каралган очракларда стационар булмаган сәүдә объектлары бүленә.».

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына ( Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенә) әлеге

000028

карарны территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланганнан соң биш көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов